ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.10.2022 ел Баулы шәһәре № 221

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булган муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләренә, белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында» 2019 елның 19 апрелендәге 104 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү буенча бердәм тариф сеткасы таралмаган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләренең, үзәкләштерелгән бухгалтерия белгечләренең һәм бухгалтерлык исәбе бүлекләренең айлык вазыйфаи окладларының күләмен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләренә, белгечләренә, үзәкләштерелгән бухгалтерияләр һәм бухгалтерия исәбе бүлекләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында» 2019 елның 19 апрелендәге 104 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 4 сентябрендәге 178 номерлы, 2020 елның 2 октябрендәге 191 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Җирле үзидарә органнарының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Мәгариф бүлегенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы бүлеге, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы яшьләр эшләре буенча бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең хезмәтенә түләү оештыру һәм шартлары турында нигезләмәдә (карарга кушымтада) 3 нче пункттагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

| «Җитәкче һәм белгеч вазифасы | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтериясе, бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлекләре өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 25 388 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 23 031 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 23 031 |
| Бүлек җитәкчесе | 18 961 | 18 961 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 16 390 | 16 390 |
| Бухгалтер | 14 997 | 14 997». |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
җитәкчесе вазифаларын
башкаручы И.И. Хөснуллина